Минзәлә шәһәре гимназиясе

Киләчәкнең башы - бүгенгедә

1998

2019 ел,ОКТЯБРЬ

киләчәкне яктырта

# Яшьлек







КӨТЕП АЛГАН КӨЗГЕ БАЛ!

# КӨТЕП АЛГАН КӨЗГЕ БАЛ!

**Сентябрь аена аяк бастыкмы, көз бәйрәме тизрәк җитүне көтә башлыйбыз. Җәй буена бакчада эшләп арыганнан соң, күңел бәйрәм тели. Бәйрәм исә үзең актив катнашсаң гына кызык була. Шуңа, тир түгеп, башта командаң өчен эшләргә кирәк.**



ТАБИГАТЬ һәрвакыт үзгәреп тора. Ел фасыллары алмашынган саен, табигать тә яңа киемнәрен кия. Менә хәзерге вакытта да үзенең алтын яфраклары белән көз килеп җитте. Бу ел фасылы башкаларыннан аеруча матур. Урманнар, болыннар үзләренә генә хас бер төскә керә. Каеннар, иң беренче булып, яфракларын коя башлыйлар, ә инде аннан соң калган агачлар да киемнәрен алыштыралар.



Гимназиядә дә көтеп алынган көзге бал бәйрәме уздырылды. Бәйрәмне оештыру өчен 9 сыйныф җаваплы итеп билгеләнде. Бәйрәм берничә этаптан торган бәйге формасында үтте.

Ярышта 5 нче, 6 нчы,7 нче, 8 нче, 10 нчы сыйныфлар катнашты. Беренче этап табышмакларга җавап эзләү белән башланды. Катнашучыларның көз темасы белән бәйле тапкырлыкларын сынадылар. Икенче этапта катнашучылар көз темасына кыска театраль күренешләр күрсәттеләр. Киләсе этап көзге уңыштан әзерләнгән тәм-томнарга багышланды. Укучылар үзләре әзерләп килгән «телеңне йотарлык» ризыклар белән авыз иттерделәр. Барысы да искиткеч иде. Соңыннан әдәби геройлар образында көзге кием бәйгесе уздырылды.

Жюри әгъзалары гадел булырга тырышты. Җиңүчеләр булып, 8 нче сыйныф табылды. Ләкин бер кеше дә бүләксез кайтып китмәде. Барлык табашычылар җиңеллек һәм күтәренке кәеф белән таралыштылар. Бәйрәм бик күңелле үтте. Мәктәп укучылары искиткеч “Көзге бал” бәйрәмен бүләк итте. Киләчәктә тә мәктәп күләмендәге бәйрәмнәр кабатланып торсын. Уку мәшәкатьләренә чумып, бер-беребез белән аралашырга да өлгерми калабыз. Ә әлеге бәйрәмнәр бер сәбәп булып тора. Уңышлар телибез.



Айзилә Муллахмәтова

# Атна шәхесе - Самат!

Атна шәхесе - Самат!



**Бу айның атна шәхесе - спортчы, креатив фикер йөртүче, кызларыбызның күңелен яуларлык, уңган-булган егетебез Самат Гыймадиев! Ул гимназиябездә 11 нче сыйныфта белем ала.**

**Туган көне:** 22.02.2002
**Яраткан фильмы:** «Темный рыцарь»
**Яраткан ризыгы:** бәлеш

**- Сәлам, Самат!**

- Сәлам.

**- Син үзеңне уңышлы кеше дип саныйсыңмы?**

- Юк, санамыйм, унышлы кеше булыр өчен, үз-үзең өстеңдә әле бик күп эшләргә кирәк.

**- Әгәр “вакыт машинасы”на утырып үткәнгә кайтып булса, син ни дә булса үзгәртер идеңме?**

- Юк, миңа барысы да ошый.

**- Әгәр дә син кеше яшәми торган утрауга эләксәң, үзең белән нинди 3 әйбер алыр идең?**

- Шырпы, скотч һәм пычак.

**- Син "Глаголица"га ничек әзерләндең?**

- Бу конкурста беренче тапкыр катнашмыйм, шуна күрә ничек әзерләнергә кирәклеген белә идем. Жюри әгъзаларына укып күрсәтер өчен, берничә шигырь яздым.

**- Гимназиядә укуы ошыймы?**

- Нормально.

**-Иң якын дустың?**

- Иң якын дустым минем - Рәзил, мин аның белән җиде яшьтән бирле дус!


**- Киләчәктә кем булырга уйлыйсың?**

- Сер… Киләчәккә планнарны сөйләргә ярамый...






Ру-


gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
gimnaziya_official
ШКОЛА ПРЕВОСХОДСТВА
gimnaziya_official
ШКОЛА ПРЕВОСХОДСТВА
Если мы сегодня будем учить так, как учили вчера, мы украдем детей завтра

# Funny Halloween!



**Good day!** I would like to say a few words about amazing and strange holiday for us-Halloween.
It is a holiday that takes place on the last October day, 31st. The word “Halloween” means “hallowed evening". The tradition of celebrating this day began in the 5th century when the Irish Celts marked this day as a day of transition from one year to the next one. It was the time when “the season of the sun” was over, and “the season of darkness and cold” began.




Nowadays Halloween is a very famous American and European holiday with its own traditions of celebration, especially among young people. The main tradition is the tradition of dressing costumes of ghost, demons and other horrible creations. Dressed children go from door to door saying «trick or treat», it's the most popular Halloween activity. The neighbours should give them little coins, sweets, fruits and after that children don't play tricks on them. The main symbol of this holiday is Jack-o'-lantern — a pumpkin with the grotesque face carved into one side. Then you should put a candle inside.

This school year we celebrated Halloween in our school. Before the holiday our class prepared colourful costumes such as witches, ghousts, skeletons, spiders and pirates and decorated the hall. During the holiday we did a lot of interesting tasks and won the prises. We danced , sang the songs and took a lot of photos.
I liked it very much. It was so funny!







Galieva Elvina, 7 form

# Туган көннәр



**Укытучылар:**
**Хәкимова Елена (15.10)**
**Хәкимҗанова Әлфия (19.10)**

**1нче А сыйныфы:**
**Нәбиуллина Афина (21.10)**
**Степанов Андрей (04.10)**
**1нче Б сыйныфы:**
**Кыямов Җәмил (29.10)**
**2 нче сыйныф:**
**Галиев Данил (14.10)**
**Даутова Ләйлә (13.10)**
**Илгачев Камил (21.10)**
**Ихсанов Аслан (29.10)**
**3 нче сыйныф:**
**Хәлимов Нурсолтан (12.10)**
**4 нче сыйныф:**
**Исмәгыйлов Ильяс (07.10)**
**6 нче сыйныф:**
**Газизова Язилә (01.10)**
**Гыйбадуллина Зәрия (24.10)**
**7 нче сыйныф:**
**Исламова Лилия (29.10)**
**10 нчы сыйныф:**
**Гыйльмиев Данил (11.10)**
**11 нче сыйныф:**
**Шакиров Рәүф (31.10)**









**Баш мөхәррир** - Крашева Рузалина
**Әдәби консультант** - Гарипова Рузиля, Мусина Язилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Маликова Камилә, Авзалтдинова Камилә, Мулләхмәтова Айзилә
**Фотокорреспондент** - Яковлева Алсу
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Галиева Лилия Альберт кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745